


**Туманская, Ольга. Яңа республикага – яңа театр / О. Туманская // Татарстан. – 2020. – №5 (341). – С. 42-45: фото**



1922 ел. Агарту халык комиссариаты Кызыл Октябрь исемендәге Беренче дәүләт үрнәк татар драма театры булдыру турында карар кабул итә. Яңа оешкан ТАССР өчен бу олы мәдәни вакыйга була. Татар мәдәнияте өчен яңа дәвер башланган чор.

20 нче елларның репертуары күпкырлы булуы белән шаккаттыра. Яңа заман каһарманнары турындагы эшләр белән беррәттән милли спектакльләр дә, рус һәм чит ил классикасы да куела – «Галиябану», «Гамлет», «Отелло», «Явыз Иван үлеме» спектакльләрендә ышандыра белеп уйный торган Хәлил Әбҗәлилов, кайнар канлы Мифтах Әбсәламов, драматик рухлы Мөхтәр Мутин, күпкырлы Гөлсем Болгарская балкый… Сезон саен афишага дистәгә якын яңа спектакль өстәлә. 1925 елда беренче милли опера – «Сания» сәхнәгә куела. Ә аннан соңгы ел үзе бер дәвергә тиң булып чыга: «Тинчурин – Сәйдәшев» дуслыгы нәтиҗәсендә «Зәңгәр шәл» спектакле туа. Ул озак елларга татар театрының брендына әверелә.



1930 еллар уртасына кадәр Мәскәү, Ленинград, Әстерхан, Орск, Свердловскида – бөтен ил буйлап! – дистәләрчә татар профессиональ дәүләт театрлары эшли, – дип сөйли Нияз Игламов. – Бер-бер артлы аларны яба башлыйлар. Татар театрын көчләп ТАССР чикләренә «куалап» кертәләр. 23 профессиональ театрдан икене генә калдыралар – Казанда һәм Минзәләдә. Репрессия машинасы татар мәдәнияте әһелләрен берәм-берәм үзенә йота, алар арасында күренекле драматурглар да, талантлы режиссерлар да, актерлар да була. Кәрим Тинчурин, Гали Ильясов, Фәтхи Бурнаш, Мөхтәр Мутин, Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Мәхмүт Галәү, Гомәр Исмәгыйлов…

Ольга Туманская «Яңа республикага – яңа театр» дип исемләнгән мәкаләсендә, әдәби бүлек мөдире, театр тәнкыйтьчесе, шулай ук татар театры тарихы белгече Нияз Игламов белән узган гасырның илһамлы 20 нче елларында һәм дәһшәтле 30 нчы елларында булган вакыйгаларны яктырта.